Пәйгамбәребезнең сәхабәләре дә үзара шаярышып, көлешеп яшәделәр. Корырак холкы белән танылган Гомәр дә гаиләсенә, хатыны-баласы янына кайтса, сабый балага әйләнә торган булган. Гомәр: «Без урамда арысланнар булсак, өйдә куяннар булдык», – диде. Бүген күп «ирләр» өйдә арыслан булып йөрсәләр, урамга чыккач, йомшак куянга әйләнәләр. Гомәр еш кына дуслары белән сөйләшеп утырганда илһамланып шигырьләр дә сөйләп алган. Көлгәндә утырган җиреннән артка егылып китә торган булган. Динебез безгә җимерек чырай, җыерылган каш белән, баш-аяк кайгыга чумып яшәргә кушмый. Киресенчә, Пәйгамбәребез Аллаһыдан, кайгы һәм күңел төшенкелегеннән сакла, дип, дога кыла торган булган.

Әмма һәр нәрсәнең үз тәртибе һәм чамасы булырга тиеш. Шәригать буенча, кешенең көлүе башка кешене мыскыл итүгә, кимсетүгә әйләнергә тиеш түгел. Пәйгамбәр: «Кешегә мөселман кардәшен кимсетүе явызлык буларак җитә», – диде (Мөслим риваяте).

Көлгәндә, шаярганда алдашырга ярамый. Күпләр шаярту белән алдашуны аерып тормыйлар. Соңыннан, мин шаярып кына әйттем бит, диләр. Пәйгамбәребез шаярды, әмма алдамады. Еш кына берәр булган хәлне сөйләгәндә дә үзеңнән өстисе, бераз су кушасы килә. Пәйгамбәребез: «Хәсрәт булсын кешеләрне көлдерү өчен ялган сөйләүчегә, хәсрәт аңа, хәсрәт аңа!» – диде (Әхмәт, Әбү Даут, Тирмизи).

Табиблар көлүне файдалы диләр, әмма бик файдалы нәрсә дә күпкә китсә, зыянлыга әйләнә. Аллаһ биргән хәләл ризыклар да файдалы, тәнгә көч өсти, әмма артыгын ашасаң, зарарлы, киресенчә, көчең китә. Йоклау тәнне ял иттерә, артыгы китсә, баш авырта. Дару төймәсен чама белән эчкән – авырудан терелә, учы белән эчкән агулана. Риза хәзрәт: «Көлү сәламәтлек өчен файдалы дип әйтсәләр дә, күп булып китсә, килешми вә акылсызлык галәмәте була башлый. Күңел уяу вакытында адәм баласының күп көләргә яратмавы табигый», – диде.

Бөтен тормышны уен-көлкегә әйләндерү дә дөрес түгел. Кайчак кешеләрдән бөтенләй җитдилек китә, бөтен очрашулар көлкегә, «иха-хай-миха-хайга» гына кайтып кала. Акыл иясе көләсе урында көлсен, әмма елыйсы урында көлү ахмаклык булып тора. Аллаһы Тәгалә ашау-эчүдә, йоклау, мал туплауда гына түгел, хәтта гыйбадәттә дә исраф итүне, чиктән ашуны тыйды. Әлбәттә, уен-көлке дә исрафка әйләнергә тиеш түгел. Гали ибн Әбү Талип: «Ашаганда ничек ризыкка тоз кушсаң, сөйләгәндә дә шулай көлке куш», – дигән. Тозсыз ризыкның тәме булмаган кебек, уен-көлкесез тормышның яме юк. Әмма шулпага тозның артыгын салсаң да, ризыкның тәме китә.

Раббым, безгә сөекле Пәйгамбәребезнең васыятьләрен ишетеп, аларны тормышыбызда кулланырга насыйп әйләсен. Безгә дөньяда да, ахирәттә дә бәхет-сәгадәт бирсен.

***Йосыф хәзрәт Дәүләтшин, Түбән Кама Үзәк мәчете имам хатибы***

*Тарих*

***Төркия күгендә Россия хәрби очкычы бәреп төшерелгән көннәрдә, ике ил арасында киеренкелек арткан вакытта, миңа Төркиягә чыгып китәргә туры килде. Бу сәфәремнең сәбәбе – Төркиядә «Күчем хан» романының төрекчә басылып ятуы һәм яңа китабым өчен материал туплау иде. Бу вакыйгаларның икесе дә Кония вилаятендә булганлыктан, башта төрек самолетында Казаннан – Истанбулга, аннан Анталиягә очтым, кояшлы Анталиядән таулар аша автобуста җилдә һәм салкынча Кониягә юнәлдем, аннан себер татарлары яшәп яткан Бөгередәлек авылына юл тоттым... Анысы сәлҗук төрекләренең элеккеге башкаласы Кония белән Төркиянең хәзерге башкаласы Анкара арасында урнашкан, һәм минем бу авылга ун елга инде өченче тапкыр килүем иде...***

# Һиҗрәт








Бу татар авылы турында мин беренче тапкыр 2007 елда Мюнхен шәһәрендә яшәүче себер татарларыннан ишеттем. Алар бирегә Икенче дөнья сугышыннан соң, эшче көчләр буларак Төркиядән килгәннәр һәм гаиләләре белән Алманиядә яшәп калганнар. Фаяз Каплан исемле милләттәшебез үзләренең себер татарлары икәнлеген, атабабаларының Төркиягә моннан йөз ел элек чукындырудан качып килгәнлекләрен сөйләгән иде. Шул җәйне Бөгередәлектә авылның йөз еллыгын уздырасылар икән, себер татарлары мине дә анда чакырды. Мин исә бу вакыйга турында Казанга, татар конгрессына кайтып сөйләдем, мәдәният министрлыгы белән элемтәгә кердек һәм Бөгередәлекнең йөз еллыгына Татарстаннан тулы бер төркем барды, мин исә Төркиягә үз хисабыма юл тоттым...

2007 елның июлендә Бөгередәлекнең йөз еллыгын бик матурлап, зурлап билгеләп үттек, бу хакта мин соңыннан матбугатта да язып чыктым. Һәм шул көннән башлап мин Бөгередәлек белән ныклап кызыксына башладым, моның тагы бер сәбәбе бар иде – себер татарларын бирегә якташлары Габдрәшит Ибраһим алып килгән, ә ул үзе зур хезмәтләр язылырга лаек зат иде! Икенче тапкыр мин Бөгередәлеккә 2012 елның маенда, Габдрәшит Ибраһим белән бәйле чараларда катнашырга дип бардым. Башта авыл башында аның исемендә хәтирәләр урманы утырттык, аннан район үзәге (илчә) Җиһанбәйледә Габдрәшит Ибраһим исемендәге парк ачтык, ә инде өлкә (ил) үзәге Кония шәһәрендә бу бөек милләттәшебезгә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция узды, анда япон, алман, төрек галимнәре катнашты, мин дә чыгыш ясадым. Һәм менә Бөгередәлеккә һәм Кониягә өченче сәфәрем, аларның икесендә дә себер татарлары күпләп яши һәм миңа алардан авыл тарихы, Габдрәшит Ибраһим турында җентекләп сорашып калырга кирәк иде... Ә аның өчен алар арасында кимендә берничә атна яшәргә, барысын да күрергә, ишетергә, теркәп барырга кирәк. Һәм мин шулай эшләдем дә...

Бүгенге көндә Бөгередәлектә өч йөз тирәсе кеше яши, аларның күпчелеге – себер татарлары, араларында төрекләр һәм көрдләр дә бар. Авыл карап торышка шактый зур күренсә дә, андагы күпчелек өйләр кышларын буш тора, аларның хуҗалары Кониядә, Анталиядә яки Европа илләрендә яши, җәйләрен исә кабат үз нигезләренә җыелалар. Бөгередәлектә бер яхшы гадәт бар – авыл халкы, кайда яшәвенә карамастан, ике гаеткә бирегә кайта, бәйрәмне бергә уздыралар, зиратны тәртипкә китерәләр. Шулай ук Бөгередәлек татарлары, кайда үлсәләр дә, мәңгелеккә үз авыллары зиратына кайтып яталар, аларны озатырга бөтен тирәяктан милләттәшләре җыела... Бөгередәлек татарларына гына хас тагы бер йола-бәйрәм бар – май аеның икенче якшәмбесендә алар, кайда яшәүләренә карамастан, авылга «Шөкранә көне»нә җыелалар, намазлар укып, догалар кылып, Аллаһка рәхмәт әйтәләр. Бу көнне фәкыйрьләргә ярдәм ителә, байлар ярлыраклар белән үзендәгене бүлешә, шунда саткан әйберләрнең акчасы да ярдәм фондларына китә. Бәйрәмнең икенче исеме дә бар икән – «Яңгыр догасы», чөнки яз башында халык яңгыр сорап, Аллаһка мөрәҗәгать итә, чөнки барысының да авыл читендә җир кишәрлекләре, өй алларында җиләк-җимеш бакчалары бар, халыкның бер өлеше шуның хисабына яши. Җәйге челләләрдә, 40-50 дәрәҗәле эсселектә яңгырның һәр тамчысы, суның һәр бөртеге биредә Аллаһ рәхмәте итеп кабул ителә.

Авылның төп су чыганагы – Бөгередәлек тавыннан бәреп чыккан мул сулы чишмә, ул торбалар белән аска да төшерелгән һәм өйләргә кертелгән. Йөз ел элек себер татарлары бу урынны нәкъ менә суы-чишмәсе, су буйларындагы яшел тал-тирәкләре, иген чәчәрлек, мал йөртерлек тигез җирләре булган өчен сайлап алган. Югыйсә, госманлы хөкүмәте дин-ислам өчен карлы Себердән эссе Төркиягә һиҗрәт кылган бу татарларга Истанбулда да, Кониядә дә яшәргә урыннар тәкъдим итеп караган. Алар исә, озак уйланганнан һәм эзләнгәннән соң, нәкъ менә шушында, авыл булып укмашып яшәүне кулайрак күргәннәр һәм Бөгередәлек тавы итәгенә килеп урнашканнар. Ул вакытта шәһәрләрдә урнашып калган булсалар, без хәзер аларның эзләрен дә таба алмас идек.

Менә мин хәзер шул Бөгередәлек тау башында басып торам...

Тау-таш араларыннан чишмә бәреп чыкканга, аны «тишек бөер» – Бөгередәлек, дип атаганнар. Хәер, авыл башта, шул замандагы солтан исеме белән – Рәшадия, дип аталган, җөмһүрият елларында исә аны хәзерге исеменә үзгәрткәннәр. Тирә-күршеләр исә аларны «Татарлар» дип йөрткәннәр. Әнә аста – шул татар авылы җәелеп ята, нәкъ уртада – манарасы күккә ашкан таш мәчет, авыл башында – йөз еллык зират, ерак түгел Габдрәшит Ибраһим урманы шаулый, Кония тарафына таба, су буйлап, яшел куаклар тезелеп киткән. Авыл уртасында туп-туры итеп салынган берничә урам шәйләнә, болары – госманлы хөкүмәте себер мөһаҗирләренә салып биргән иске авылдан калган урамнар. Тирә-юньдә - тау тезмәләре, көнчыгышта – Дуутәпә, көнбатышта – Күктәпә, алар арасында көрд авыллары урнашкан.

Биредән Кониягә - 135, илчә-район үзәге Җиһанбәйлегә - 35 чакрым. Якын-тирәдә ник бер татар авылы булсын! Ул заманда һиҗрәт кылган казан татарлары да Иске шәһәр тирәсенә урнашалар, ә ул биредән йөзләрчә чакрым ераклыкта. Ә туган ил – Себер – аннан да ерак, менә шушы биек таулар, тирән диңгезләр, кара урманнар артында... Һәм ак карлар арасында туган, яшел болыннарда яшәгән, кара урманнарның сайрар кошы булган себер татарлары хәзер шушы тау-таш арасында тамыр җибәрергә, тормыш башларга, мәңгелеккә төпләнергә тиешләр... Нәрсә мәҗбүр иткән соң йөзләгән татарны шулай салкын кыш уртасында гаиләләрен, балаларын, әби-бабаларын алып, кубарылып илдән чыгып китәргә?

Себер татарларының бу һиҗрәте турында матбугатта берничә язма булды, Төмән телевидениесе алар турында «Кантуган» дип аталган документаль фильм да төшерде, шулай ук Казан телевидениесе дә Төркиядәге себер мөһаҗирләре турында сюжетлар күрсәтте. Әмма алар да бу бөек күченүнең төгәл вакытын һәм сәбәпләрен ачып бетерә алмадылар. Минем бирегә кабат килүемнең дә төп максаты – шушы бушлыкны тутыру, өлкән буын исән вакытта, ул еллар турында күбрәк мәгълүмат туплап калу иде. Шунысын да әйтеп китәсем килә, себер татарларының бу һиҗрәте турында Төркиядә берничә китап-брошюра да дөнья күрде, аны милләттәшләребез үзләре язган. Бөгередәлек авылының интернет-сайтында да себер татарларының Төркиягә һиҗрәте турында драма әсәрләре һәм поэмалар, аерым мәкаләләр куелган. Әмма боларда да буталчыклар шактый, төп сүз үз нәселләре һәм бар кешегә билгеле вакыйгалар турында гына бара. Алай да, һәр китаптан нидер табарга, чагыштырырга, этәргеч алырга мөмкин. Шушы хезмәтләр белән якыннан танышканнан һәм Бөгередәлектә, Кониядә дистәләгән кеше белән очрашканнан соң, шулай ук бу мөһаҗир татарларның туган якларында – Омск өлкәсенең Большеречье районы авылларында, Габдрәшит Ибраһимның туган шәһәре Тарада булганнан һәм галимнең үз хезмәтләре белән танышканнан соң, мәсьәләгә бераз ачыклык кергән кебек булды.

Гадәттә тарихчылар казан татарларының Төркиягә һиҗрәтен 1897 елгы беренче халык санын алу белән бәйлиләр, Мәхмүт Галәү дә үзенең «Мөһаҗирләр» романында шуңа басым ясаган. Имеш, татарлар моны яңа чукындыруга әзерлек, дип кабул иткәннәр һәм иманнарын саклау өчен, Төркиягә күчеп киткәннәр. Әмма Россиядә татарларны көчләп «христиан дине вәкилләре» дип теркәү һәм яңадан исламга кайткан өчен эзәрлекләүләр 1860-1870 елларда иң югары ноктасына җиткән була. Шул сәбәпле, ул вакытта Сахалин каторгалары чукынырга теләмәгән мөселман-татарлар белән тула, чукындыруга каршы эшләгән татар муллаларын Себернең Турухан краена дистәләп-дистәләп судсыз-нисез сөрәләр. Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәре дә шушы фаҗигале хәлләрне тасвирлый. Димәк, татарларның иманны һәм гомерне саклап калу өчен һиҗрәтләре инде шушы көчләп чукындыруларга җавап булып тора. Һиҗрәт – ул инде нәтиҗә.

Йөзләгән себер татарларының егерменче гасыр башында динислам хакына мәңгегә туган якларын ташлап китүләре дә - гасырлар буе аларга карата алып барылган рәхимсез чукындыруларның ачы нәтиҗәсе ул. Аларда да бу хәрәкәт инде унтугызынчы гасыр азакларында башланган булырга тиеш, әмма ил-йөрт белән һиҗрәткә кузгалу берничә елдан соң гына башкарыла. Моның сәбәпләре дә бар. Аерым кешеләрнең китүен артык тоткарламаса да, йөзләгән татарның, аларга карата алып барылган чукындыру сәясәтенә протест йөзеннән илне ташлап китүләренә Россия каршы чыга. Бу татарларга тиешле документлар бирелми, урыннарда һиҗрәт хәрәкәтенә каршы эшләр башлап җибәрелә. Шулай итеп, милләт тә икегә бүленә - берәүләр иманны саклап калу өчен Төркиягә күчеп китүне хупласа, икенчеләр моңа кискен рәвештә каршы төшә. Һиҗрәткә әзерләнгән Аубаткан (Яңавыл), Яланкүл, Үләнкүл, Кумыслы, Чабаклы, Койгалы, Кушкүл, Каракүл, Чарналы сибертатар авылларында да шул хәл күзәтелә, гаиләләр, ата-аналар, балалар бер фикергә килә алмыйлар.

Бу урында себер татарларын һиҗрәткә күндерүдә танылган якташлары Габдрәшит Ибраһимның да роле зур булуын әйтеп үтәргә кирәк. Ул Россиядә мөселманнарның хокукы авыр шартларда яшәвен Төркия солтаннарына да сөйли, бу хакта чит ил матбугатында аерым мәкаләләр, хәтта китаплар да бастырып чыгара. 1905 елгы күтәрелештән соң халыкта бераз өмет кабынса да, Россиядә 1907 елларда башланган кара реакция чоры мөселманнарда бу илгә карата берничә өмет калдырмый. Ул арада Габдрәшит Ибраһимның үзен дә бер елга крепостька ябарга, дигән суд карары чыгаралар, ул илне ташлап качарга мәҗбүр була. Шушы вакытта Габдрәшит Ибраһим яшерен рәвештә туган якларына кайтып килгән һәм фикердәшләренә илдәге вәзгыятьне аңлаткан булырга тиеш.

***Фәүзия Бәйрәмова, язучы, тарих фәннәре кандидаты***
***2015 ел – декабрь, 2016 ел – гыйнвар***
***Төркия-Татарстан***

**Дәвамы бар**

*Шәхесләр*

# Авылдашым Факия

***Фагыйлә Чумарова***

***Җәйге каникуллар башланды гына, алда – өч ай буена рәхәтлектә чумасы, көнозын елгада коенасы, урманга җиләккә барасы – бала-чагага бәхетле булыр өчен тагы нәрсә кирәк? Бер төркем кызлар җыелыштык та, көн тәртибендә нәрсә барлыгын тикшерә башладык. Арабыздан кемдер әйтеп куйды: «Факия кайткан бит, сез ишеттегезме әле ул хәбәрне?» Шунда ук шау-шу купты: «Факия кайтканмыни? Әйдәгез тизрәк, ул инде безне көтәдер», - дип, урам тутырып, тузан туздырып, Хәбир абыйлар йортына таба чаптык. Чынлап та, без килеп җиткәндә, Факия капка янындагы эскәмиядә утырып тора иде. Без, шаугөр килеп, аның белән кызларга гына хас нәзакәтле назлылык белән кочаклашып күрешә башладык.***



*Сулдан икенче Факия Шихова*

Авыл уртасында клуб каршысында гына Рузи бабай белән Әминә әбинең уллары Хәбир абый төп йорт каршында үзенең ишле гаиләсе өчен бик матур йорт төзеп куйган иде. Хатыны Мәймүнә апа белән алар аз да түгел, күп тә түгел, дүрт ул һәм өч кыз бала тәрбияләп үстерделәр. Олы уллары Фәрит абый белән олы кызлары Галия апа инде буй җиткән егет-кыз иделәр; бергәләп уйнап үскән Вәлия, аннан кала Факия – безнең яшь арасы бер-ике ел гына булгач, безгә үзара дус булу мәслихәт иде. Аннан соң өч малай - Шәриф, Зиннур һәм Тәүхит үсеп киләләр.

Менә шул ишле гаиләнең җиде бала арасыннан Факия гарип бала булды. Дөньяга килгәчтен үк, полиомиелит эпидемиясенә дучар булып, аның аякларына паралич зәхмәте кагылды, аяклары бернәрсә тоймас булдылар, атлап китә алмадылар. Кечкенә вакыттан бирле Факияне зур шәһәрләргә табибларга күрсәтергә дип йөрттеләр, мәктәпкә барыр вакыт җитәрәк, аның аякларына бик авыр, калын табанлы ботинкаларга беркетелгән протезлар киертеп, ике култык таягына таянып булса да, йөрергә өйрәтеп карадылар. Беренче классны ул авыл мәктәбенә укырга йөрде. Аннан соң аны Новосибирски шәһәрендәге физик мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен төзелгән интернат-мәктәптә укыттылар. Минем хикәям Факиянең менә нәкъ шул мәктәптән җәйге каникулга кайткан минутларын искә төшерүдән башланган иде. Туган авылыннан, туган йортыннан, әти-әнисе яныннан аерылып, үзе белмәгән телдә сөйләшүче чит-ят балалар янына китүләре ничек кыен булгандыр – аларны хәзер тасвирлап бирә алмыйм... Бу турында мин бик соң уйлый башладым, ул вакытта без әле андый нәрсәләр турында сөйләшә белми идек. Беренче класста укыган вакытында мәктәпкә әллә китереп куйдылар микән – анысын тәгаен хәтерләмим, әмма мәктәптән соң без аны озатып куядыр идек. Китаплар салынган букчадан кала, кулда җиңел аяк киеме өчен, бераз капкалап алыр өчен азык-төлек салынган капчыклар, китап-дәфтәрләрне буямасын дип, кара савыты өчен аерым капчык күтәреп йөрергә туры килә иде. Кемдер Факиянең сумкасын ала, кемдер капчыгын ала – шулай күмәкләшеп, Факияне озатып куябыз. Хәтеремдә, аның хәленә бераз керер өчендер инде, юатыр сүз тапмаганнандыр, аның култык таякларына атланып, чикерткә кебек бераз чапкандай иттем дә, әйтәм үзенә:

- Сиңа, Факия дустым, рәхәттер инде, аякларың белән йөрергә кирәкми, шул таяклар белән сикереп йөрү җайлырактыр, мин дә шулай йөрер идем, - дигән булам... Аның җавабын беркайчан да онытасым юк:

- Ә минем аякларым сезнеке кебек таза булса, мин бер дә аягыма кимәс идем, гел яланаяк кына йөгереп йөрер идем. Хәтта кар өстеннән! – дип өстәп куйган иде. Аннан соң, без кыбырсый башласак, әйтә:

- Барыгыз инде, чабыгыз чабасы җирегезгә, гел минем янымда гына утырып торып булмый бит!

Хәзер менә бу сүзләрне язам, ә үзем күз яшьләремә буылам. Дус булып йөреп тә, без, чынлыкта исә, аның эчке кичерешләрен, аһ-зарларын бөтенләй белмәгән булып чыгабыз икән бит! Чөнки ул беркайчан да зарланмады, беркайчан да күз яше белән еламады. Беркайчан да мин китекмен, мин гарипмен, дип, үз-үзен кимсетмәде, үзенә ташлама сорамады. Ничектер, гаиләдә дә аңа карата аерым караш булмады, аны – ул гарип бит! – дип иркәләмәделәр, йорт эшләреннән читләштермәделәр. Еллар уза торды. Бер заманны без дә үсеп җиттек, таралыша ук башладык... Бер дә бер елны, 1977-1979 еллар арасында, туган авылыма кайткач, клуб каршындагы йортның бөтенләйгә тынычланып, ятимләнеп калганлыгына игътибар иттем... Хәбир абый ишле гаиләсен, карт әнисен алып, Казахстан җирләренә, Җамбул шәһәренә күчеп киткән булып чыкты. 1981 елны мин аларны эзләп, Җамбулга барып кайттым. Әмма шул баруымда Факия өйдә туры килмәде, безгә очрашу насыйп булмады. Тормыш агымында бөтенләй бер-беребезне югалтып торган вакытлар да булды, имеш-мимешләр белән генә хәбәрдар булган вакытлар да булды.

Бүгенге тормышыбызда интернет дигән замана могъҗизасы безгә ярдәмгә килде – без бер-беребезне эзләп таптык! Аралар һаман ерак калса да, интернет аша еш хәбәрләшергә, бер-беребезне күреп, аралашырга мөмкинлек туды. Зур гаилә башлыгы Хәбир абыебыз берничә ел элек бу фани дөньялардан китеп барган икәнлеген белдем. Мәймүнә апа исән-сау балалар кадер-хөрмәтендә бәхетле картлыгын каршы алган, балалар барысы да үз гаиләләре белән, үз көн-күрешләре белән төрлесе-төрле якларга таралышып яшәп яталар икән. Ә минем балачак дустым Факия Тараз шәһәрендә (Җамбулның хәзерге исеме) үз тормышы белән яши икән.

...Зур кызыксыну белән Факиянең тормышын чагылдырган фотоларны карыйм. Аның йөзе элеккечә тынычлык, сабырлыкны чагылдырган елмаю белән бизәлгән. Култык таяклары күренми – ул инвалидлар коляскасында утырып тора. Менә аның өстендә бик затлы күлмәк, ул зур залда, коляскада утырган килеш, зифа буйлы чибәр егет белән биеп йөри. Менә ул ниндидер чит ил шәһәрендә – шуны раслаучы реклама щитлары, кибетләр, кафелар чагыла... Минем игътибарым көчәйгәннән көчәя генә барды – кайларда йөри минем балачак дустым? Нәрсә белән шөгыльләнә? Бер дә картлыгын көтеп, мескенләнеп утырган гарип хатынга ошамаган, киресенчә, бик бәхетле, бай рухи тормышлы кеше йөзен чагылдыра түгелме?

- Мин үземне кызганмаска бәләкәй чактан ук өйрәндем. Рәхмәт әти-әниемә, туганнарыма, алар да мине аерып, гарип икәнлегемә басым ясап тормадылар, нәрсә генә булса да, иң беренче җаваплылык минем үз өстемдә икәнлеген аңлаттылар. Урта мәктәпне бетергәч, тегүче һөнәрен сайлап алдым. Шулай да, кайчан да булса аякка басу теләге көчле булганлыктанмы – һаман төрле операцияләргә ризалаша идем, шунлыктан яшьлегем гел бер больницадан икенчесенә күчеп, бер операциядән икенчесен кичереп узды. 28 яшемдә мин беркайчан да аякка баса алмаячагыма төшендем, ә врачлар өстәмә операцияләрне бары тик үзләренең фәнни эшләре өчен ясап килүләрен аңладым. Яшьлегем узган, ә минем әле үз тормышымда бернинди үзгәреш күренми. Мин үз алдыма максатлар куйдым – гаилә корырга, квартира ягын кайгыртырга һәм хатын-кызның иң зур вазифасын үтәргә, ягъни бала табып үстерергә булдым. Хезмәтемне дә үзгәрттем – бухгалтерлыкка укып чыгып, яңа кәсебем буенча эшкә кердем. Мин үз тиңемне очрату бәхетенә ирештем – яратып кияүгә чыктым, икебез өчен зур шатлык алып килгән улыбыз Рузи дөньяга килде. Әмма, нишләтәсең, тормыш бер алдын күрсәтсә, бер артын күрсәтә. Минем ирем, баламның әтисе, бу якты дөньялардан китеп барды... Сыгылып төшеп, кара кайгыга батып утырырга ярамый иде – Ходайдан сорап алган улымны үстерәсе, аңа белем бирәсе бар бит – мин тагы тормыш дилбегәсенә чат ябыштым. Шулай да, тормыш гел эштән, кайгырту-борчылулардан гына торырга тиеш түгел, анда матурлык та булырга, тиеш! дип эзләндем. Үземне рухи яктан үстерү теләге бер дә саекмаган иде. Иң беренчедән, интернетны үзләштерергә булдым. Интернет бик күп мәгълүматлар алып килде, күп нәрсәгә өйрәндем. Бер заманны күземә мине таң калдырган видеоролик чалынды. Шул роликта минем кебек инвалидлар коляскасында утырган хатын белән сәламәт ир-егет искиткеч матур музыкага биеп йөри иделәр. Бу күренеш мине таң калдырды, йокыларымны качырды. Бар уй-хыялларым шул тирәдә урала башлады. Мин бу пар белән кызыксындым, алар турында күп укыдым, ниһаять, үзем өчен байтак мәгълүмат җыя алдым. Соңыннан: «Ә нишләп соң миңа да биергә өйрәнмәскә?» - дигән карарга килдем. Тагын шул ук интернет аша шул юнәлештә эшләүче хореографларны эзли башладым. Ниһаять, минем соравыма Светлана Тулибек исемле хатын җавап бирде, ул минем белән эшләп карарга әзер икәнлеген белдерде. Әмма безнең уртак теләк шунда ук комга терәлгән көймә хәленә килде: биер өчен минем утырып йөргән коляскам ярамый булып чыкты, аңа бөтенләй икенче коляска – спорт кануннарына яраклаштырылган, бик җиңел, йөртергә җайлы махсус коляска кирәк булып чыкты. Безнең Светлана белән бергәләп теләгән теләкләребез ходай рәхмәте белән чишелеп тә куйды – ирле-хатынлы бер пар миңа шундый коляска алырга ярдәм итәчәкләрен белдереп, хат язып җибәрделәр.

Светлана мине күп нәрсәләргә өйрәтте, әмма минем тагы да үсәсем килде, чемпионатларда катнашасым килү теләге дә бар иде. Парлы биюдә ир кеше белән хатын кыз күзаллана. Парсыз гына чемпионатка кертмиләр дә, әзерләнеп тә булмый. Мин тагын интернет аша Тараз шәһәрендә булган бию коллективларын барлый башладым. Күпсанлы биючеләр арасыннан Серж Аванезов исемле тренер-хореографны сайлап алып, аңа үземнең теләгемне белдереп, хат язып җибәрдем. Серж минем белән очрашырга риза булды. Сөйләшенгән вакытта без беренче тапкыр күрештек. Сержга мин үземнең коляскада утыручы инвалид хатын икәнлегем турында язмаган идем – аның беренче реакциясен күрү минем өчен мөһим иде. Беренче күрешү Серж өчен эзсез калмады, мине күргәч, аның күзләре зур булып ачылды, гаҗәпләнүаптырашта калуы йөзенә бәреп чыкты. Әмма ул «юк», дип әйтмәде, борылып китмәде. Без аның белән озак сөйләштек, мин аңа үзем күргән роликны күрсәттем, үземнең дә биергә теләгем зур булуын аңлаттым. Серж, бик яшь булуына карамастан, минем хәлемә керә алды, минем проектым белән кызыксынды һәм... без тренировкаларны башлап җибәрдек. Беренче зур чыгышыбыз - 2011 елда Белорусиядә уздырыласы халыкара конкурста катнашырга җөрьәт иттек. Безнең тырышлыгыбызның нәтиҗәсе буларак, «Венский вальс» биюен күрсәтеп, 2 урынга лаек булдык. Безнең өчен беренче һәм бик зур җиңү! Безнең бу беренче адымыбыз зур спорт юлына чыгарга юллама булган икән – 2012 елда безне Мәскәүдә уздырыласы Параолимпик чемпионатта катнашырга чакырдылар, аннан без алтын медаль белән җиңү яулап кайттык. Шул җиңүебез безгә Япониягә юл ачты, Сеул, Белград, Минск, Уфа шәһәрләрендә, Голландиядә булырга туры килде. Шул елларда мин коляскада бию серләренә төшендем, үземне профессиональ яктан үстерә алдым. Мин инде үзем генә биеп йөрүгә риза түгел идем – башкалар турында уйлый башладым. Күпме хатын-кыз төрле сәбәпләр аркасында коляскага утырырга мәҗбүр булалар! Күпмеләре, шул кайгыны күтәрә алмыйча, дөнья матурлыгын күрергә теләмичә, яшәүдән баш тартырга әзерләр! Минем аларга ярдәм кулын сузасым килде, алар алдында яңа мөмкинлекләр тудырасым килде. Хәзер минем үз бию төркемем бар, мин аларны төрле шәһәрләрдә уздырыласы чемпионатларга алып чыгарга әзерлим, төркемгә яңа кешеләр килүен, алар да бу эшнең үзләре алдында гына түгел – башкалар алдында да җаваплы икәнлеген төшенсеннәр, бүтәннәргә дә яшәргә көч биреп торырлык тәҗрибә тупласыннар дип тырышам.

Факия хәзер Тараз шәһәрендәге «Казахстанның инвалидлар бердәмлеге оешмасының» директоры, баш тренер. Аның вазифалары күпкә арткан – аның җаваплылыгында Астана шәһәренең медицина коллиятендә укучы 19 яшьлек студент улы Рузи генә түгел: Тараз шәһәрендәге һәр гарип бала өчен дә ул үзен җаваплы дип саный. Аларны инвалидлар өчен коляскалар белән тәэмин итү, укыту, сәламәтлекләре турында кайгырту кебек бик күп эш аның кул астында.

1958 елда Чарналы авылында, гади генә эшче гаиләсендә Шихов Хәбир Рузи улының гаиләсендә сәламәтлеккә туймаган кыз бала дөньяга килгән. Физик яктан кимсетелгән булса да, рухи байлык бу кызда ун кешегә җитәрлек иттереп бирелгәндер, ахрысы! Кемдер әйтер, «андыйлар хәзер күп бит», дияр һәм ялгышмас. Әмма Факия минем өчен бердәнбер, чөнки мин аның белән бергә уйнап үстем, бер күл суын эчтем, ана телебездә бер үк җырлар җырлап өйрәндем – шунлыктан ул минем өчен кадерлерәк тә, маяк булырлык яктырак та!

*Достижение*

# «Теперь нужно покорять новые высоты!»

***Динара Каримова***

***29 ноября в концертно-развлекательном комплексе «Пирамида» в г. Казани прошел гала-концерт Международного телевизионного конкурса молодых исполнителей «Татар моңы-2015», в котором наш друг Шахзат (многолетняя наша дружба с ним началась в ансамбле «Умырзая», многие знают его как Шахзода Розметова) стал лауреатом III степени! Но обо всем по порядку!***




Впервую очередь, хотелось бы немного рассказать о самом конкурсе. «Татар моңы» проводится 7-й год и уже обрел свое «лицо», став известным далеко за пределами Татарстана. Целью конкурса является сохранение и развитие национальной культуры Татарстана, привлечение молодежи к национальному творчеству, поиск молодых талантов и их поддержка. В этом году, по словам организаторов, бюджет конкурса составил 4 млн. рублей. Из них 1 млн. рублей – призовой фонд. На конкурс «Татар моңы» поступило 302 заявки – это вдвое больше, чем в прошлом году. По результатам отборочных туров во второй тур конкурса прошли 74 конкурсанта из России и стран СНГ.

По сравнению с предыдущими годами, конкурс вышел на более высокий уровень. На этот раз организаторы сделали второй и третий туры телевизионными, когда участники соревнуются в прямом эфире, далее - интерактивное голосование, где зритель мог отдать свой голос понравившемуся исполнителю, и, наконец, гала-концерт, где участники показывают свой профессионализм и получают заслуженные ценные награды!

Уважаемые читатели, предлагаем вашему вниманию рассказ о конкурсе из первых уст!

***- Шахзат, расскажи, пожалуйста, почему ты решил участвовать в этом конкурсе?***

- Я принял это решение не из-за ценных призов, не ради места, а ради самого процесса подготовки к конкурсу. Понимаете, для меня, как для артиста, певца, это что-то особенное! Ты чему-то учишься, узнаешь много нового и, конечно, развиваешь свои творческие способности и растешь в профессиональном плане.

***- А как ты готовился к конкурсу?***

- Занимался вокалом по несколько часов в день, также работал с преподавателями. Во время самого конкурса организаторы подготовили для участников мастер-классы с народными артистами Республики Татарстан, преподавателями, которые я с удовольствием посещал.

***- Шахзат, II тур был телевизионным и шёл в прямом эфире, волновался ли ты перед выступлением?***

- Конечно же, волновался, но мысленно я дал себе установку: «выступить достойно». Честно, хотел оправдать доверие тех, кто поддерживал.

***- Но у тебя ведь уже были сольные концерты, ты выступал перед широкой публикой, эмоции чем-то отличаются?***

- Во время выступления в зале определенное количество зрителей, но когда ты представляешь, что тебя видит многомиллионная аудитория канала «ТНВ», тогда эмоции зашкаливают, и ты осознаешь всю ответственность своего выступления. Все проходило в прямом эфире, и ошибиться мы уже не могли!

***-А какие песни или песню ты исполнял?***

- На разных этапах исполнял разные песни, как народные, так и авторские, но прошел я с песней «Идел буе каеннары».

***- Как оценивался второй этап конкурса, и кто был в составе жюри?***

- В этом году ввели новшество, мы не знали и не видели членов жюри, они за нами, можно сказать, следили и подслушивали! Как нам сообщили, они наблюдали за исполнителями из специально оборудованной комнаты. Также проходило зрительское смс-голосование.

***-Интрига такая!***

- Да! Но я был спокоен почему-то, было какое-то ощущение радости.

***- Следил за голосованием?***

- Не следил, просто не было времени! В песню я вложил душу и надеялся, что зрители это увидят, услышат и оценят!

***-А как ты узнал, что прошел в III тур?***

- После всех выступлений второго этапа начали награждать тех, кто выбыл после второго тура и не прошел в третий. В этот момент, конечно, не хотелось уже уходить! Я не услышал своего имени среди дипломантов второго тура и был безумно рад этому!

***- Ты до самого выступления на гала-концерте не знал, какое место займешь?***

***Как длилось ожидание?***

- Да! Но в этом и был весь интерес, вся интрига, как в любом настоящем конкурсе! А песню свою спел дуэтом, получилось своеобразно и необычно. Подготовка к гала-концерту была очень серьезная, всех артистов поделили на дуэты, трио, ведь время эфира ограничено.

***-Доволен ли ты результатом?***

- Да, очень, приятно, когда видишь положительные результаты своей работы! Самое главное - не зря работаю! Приятно, что не только родные и друзья меня поддерживали, но и абсолютно незнакомые люди голосовали за меня, писали, это очень приятно.

***-За время конкурса успел подружиться с участниками?***

- Подружился, но не со всеми так тесно, так как у нас был очень плотный график, много репетиций, мастер-классов и просто не было времени, надеюсь, что наши творческие пути пересекутся ещё не раз!

***- На будущий год планируешь еще раз участвовать?***

- Так как я стал лауреатом, то еще раз участвовать в этом конкурсе не имею права, ведь я уже достиг вершины. Теперь нужно покорять новые высоты!

***-Какие планы на будущее?***

- Планы огромные, но раскрывать всего не буду, сами узнаете… Не люблю рассказывать, а сразу делаю.

От себя хочу добавить, что в этом году гала-концерт был действительно грандиозным! Концертные номера сопровождались красочным видеорядом, где можно было увидеть архивные кадры, связанные с творчеством легендарных татарских композиторов, а также с историей создания их лучших песен. Победители «Татар моңы» этого года продемонстрировали слушателям прекрасные вокальные данные. А когда знаешь, что там выступал человек, который еще совсем недавно пел и танцевал вместе с тобой в нашем народном ансамбле «Умырзая», а теперь покоряет такие высоты, то чувствуешь гордость! Пожелаем Шахзату творческих успехов!

## КОТЛЫЙБЫЗ

Омскида яшәүче **Хәсип кызы Нәчия Садыкованы** ихлас күңелдән гыйнвар аенда булып узган 60 яшьлек юбилее белән тәбриклибез. Кадерле классташыбыз! Ныклы сәламәтлек, күңел тынычлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, якыннарыңның күңел җылысын тоеп, бәхетле озын гомер кичерүеңне телибез! Гомернең һәр мизгеле бары тик шатлык, тынычлык китерсен! Туачак таңнарың һәрвакыт нурлы, күк йөзең һәрвакыт аяз булсын.

**Иң изге теләкләр белән классташларың**

Омски шәһәрендә яшәүче **Риза кызы Шакирә Бахтиярованы** ихлас күңелдән 60 яшьлек юбилее белән тәбрик итәбез! Кадерле классташыбыз! Ныклы сәламәтлек, бәхетле-шатлыклы озын гомер телибез, балаларыңның, оныкларыңның кадер-хөрмәтендә, тигез, тыныч, мул тормышта яшәргә насыйп итсен Ходай. Һәр көн сиңа бәхет алып килсен, тормыштан тәм табып яшә, картаерга һич тә ашыкма!

**Иң изге теләкләр белән классташларың**



Большеречье районы Үләнкүл авылында яшәүче **Назыр улы Фәрид Муралеевны** 2 февральдә булачак олы юбилее – 85 яше белән чын күңелдән котлыйбыз! Кадерле әтиебез, олы юбилееңда бары тик изге теләкләребезне юллыйбыз. Исәнлек, саулык, тормыш шатлыгы, күңел тынычлыгы, тән сихәтлеге телибез. Гомерне еллар билгеләми – яшәү дәрте булсын күңелдә. Авырмый, кайгы-хәсрәт күрми, озын гомер итүеңне язсын Ходай!

**Иң изге теләкләр белән кызлары, кияүләре һәм оныклары**



Большеречье районы Үләнкүл авылында яшәүче **Вазыйх кызы Нәярә Мусагитованы** 17 гыйнварда булып узган матур юбилее – 60 яше белән чын күңелдән котлыйбыз. Һәр көн сиңа бәхет алып килсен, тормыштан тәм табып яшә, картаерга һич тә ашыкма! Күңел тынычлыгы, саулык-сәламәтлек белән балаларың, оныкларыңның уңышларына шатланып яшәргә язсын. Ходай саулык, тән сихәте, күңел тынычлыгы насыйп итсен иде.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, балаларың, оныкларың**



Тара районы Олы Уыш авылында яшәүче **Сулейманов Гыйрфан Фоат** улы 11 февральдә 60 яшьлек юбилеен бәйрәм итә. Туган көнең февраль сыман буранлы, күңелле, йолдызлы, айлы булсын. Һәрвакыт күңелең күтәренке, саулыгың нык, кулларың көчле, мәхәббәтең якты, йөрәгең кайнар булсын. Инде лаеклы ялга китәсең. Аллаһы Тәгалә барлык теләкләреңне тынычлыкта, муллыкта озын гомер кичәргә насыйп итсен.

**Иң изе теләкләр белән хатыны Нәсфия, 2 улы, 2 килене, оныгы Эльдарчик**

ОМСКИ ТАТАРЛАРЫ ГАЗЕТАСЫ
ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

**Учредитель:**
Алимбаев Тамир Алимбаевич.
**Издатель:** Омская городская татарская национально-культурная автономия, г. Омск.
**Редактор:** Г.Р. Ахмерова.
**Дизайн, верстка:** Н.А. Балько.

**Корректоры:**
Е.И. Петрова, Н.В. Кучукова.
**Редакционная коллегия:** Т.А. Алимбаев, С.С. Мирхалеева, Р.М. Сайганова, З.С. Ахмадеева, С.И. Анненкова, Ф.А. Чумарова.
**Адрес редакции**:
644016, г. Омск, ул. Семиреченская, 102.
Телефон: (3812) 550-416, факс: 55-12-00.
E-mail: tatar_mir@mail.ru

Распространяется бесплатно.
**Тираж:** 2500 экз.
Подписано в печать по графику, фактически в 15.00 20.01.2016 г.
Отпечатано в ОАО «Советская Сибирь»
644042, г. Омск, пр. К. Маркса, 39
Газета зарегистрирована Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций (Роскомнадзор).
**Св-во ПИ №ФС77-45771 от 6.01.2011 г.**

Редакция не несет ответственности за использование товарных знаков, за достоверность информации, опубликованной в рекламных объявлениях и присланных материалах.

Присланные рукописи и другие материалы не возвращаются. Перепечатка и другое воспроизведение материалов газеты «Татарский мир» возможны только с письменного разрешения редакции.